**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменения в статью 4 Закона Республики Татарстан «О порядке опубликования и вступления в силу законов Республики Татарстан и других актов, принятых Государственным Советом Республики Татарстан и его Президиумом»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
22 апреля 2019 года

**Статья 1**

Внести в статью 4 Закона Республики Татарстан от 6 августа 2003 года № 27-ЗРТ «О порядке опубликования и вступления в силу законов Республики Татарстан и других актов, принятых Государственным Советом Республики Татарстан и его Президиумом» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2003, № 8; 2011, № 6 (I часть); 2013, № 4 (I часть); 2014, № 7, № 12 (IV часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 25 (часть I) изменение, изложив часть вторую в следующей редакции:

«Официальными являются также тексты законов Республики Татарстан, актов Государственного Совета Республики Татарстан и его Президиума, включенные в интегрированный полнотекстовый банк правовой информации (эталонный банк данных правовой информации), и тексты актов Государственного Совета Республики Татарстан и его Президиума, опубликованные в «Ведомостях Государственного Совета Татарстана».».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
29 апреля 2019 года
№ 37-ЗРТ

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында” Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 22 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында” 2003 елның 6 августындагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2011, № 6 (I өлеш); 2013, № 4 (I өлеш); 2014, № 7, № 12 (IV өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш), икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

“Интеграцияләнгән тулы текстлы хокукый мәгълүмат банкына (хокукый мәгълүматның эталон белешмәләр банкына) кертелгән Татарстан Республикасы законнарының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы актларының текстлары һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, аның Президиумы актларының “Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы”нда бастырып чыгарылган текстлары шулай ук рәсми була.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 29 апрель
№ 37-ТРЗ